# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Ромодан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Ромодан авыл торак пунктында
2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2022 елның 11октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендәҗирлеүзидарәоештыруныңгомумипринципларытурында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федеральзаконның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасындаҗирлеүзидарәтурында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясынигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципальрайонының «Ромодан авыл җирлеге» муниципальберәмлегенеңРомоданавылторакпунктындагражданнарҗыены
**КАРАР ИТТЕ:**

1.2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Ромодан авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәгеРомоданавыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- тракторны карап тоту, асылмалы җиһазлар сатып алу;
-су челтәрләрен карап тоту;
- урамнарны яктыртуны карап тоту;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Ромодан авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Ромодан авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнарҗыенындарәислекитүче,
Алексеевск муниципаль районы
Ромоданавылҗирлегебашлыгы ____________ И.А.Чекалина